**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.02.2016 № 78

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 21 мартында теркәлде, № 3236

Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге
хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча
эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан
икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга
һәм аларның гаилә әгъзаларына
башка җирлеккә күчеп урнашуда
булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында

"Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында" 1991 елның 19 апрелендәге № 1032-1 Россия Федерациясе законына, "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында" 2013 елның 7 мартындагы № 92н боерыгына туры китереп **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын (алга таба – административ регламент) расларга.

2. Административ регламентның Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез

гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша күрсәтү өлешендәге пунктлары КФҮ һәм Татарстан Республикасының халык мәшгульлеге хезмәтләре дәүләт учреждениеләре арасында килешү имзаланганнан соң көченә керә.

3. Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренә: административ регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары К.А. Таҗетдиновага йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.02.2016 ел, № 78 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Административ регламент) Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халык мәшгульлеге үзәге) юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бердәмлеген, тулылыгын, сыйфатын һәм тигез итеп күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү максаты белән эшләнде.

1.2. Административ регламент халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибен һәм халык мәшгульлеге үзәкләренең, халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча аларның дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүдә үз вәкаләтләрен үтәгәндәге гамәлләре (административ процедуралар) эзлеклелеген билгели.

1.3. Дәүләт хезмәте алучылар (гариза бирүчеләр) булып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар (алга таба – эшсез гражданнар) тора.

1.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат халык мәшгульлеге үзәкләре биналарында турыдан-туры, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, автоматик рәвештә мәгълүмат бирүне дә кертеп, электрон элемтәдән яки телефон элемтәсеннән файдаланып, мәгълүматлы материаллар (брошюралар, буклетлар һ.б.) бастырып чыгару, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре (алга таба – Интернет челтәре) ярдәмендә (“Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы” (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасын һәм (яки) “Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы” (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) республика мәгълүмат системасын да кертеп), шулай ук дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре аша бирелә.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар, учреждениеләр һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар бу Административ регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

1.6. Халык мәшгульлеге үзәкләре шимбә һәм якшәмбедән, эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш көн саен эшли. Эш сәгатьләре халык мәшгульлеге үзәгенең эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән.

1.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Халык мәшгульлеге үзәкләре бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык), ХМҮнең рәсми сайтында (http://www.mtsz.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://www.uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru);

3) дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләргә мөрәҗәгать итеп;

4) Министрлыкка, халык мәшгульлеге үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефоннан);

5) халык мәшгульлеге үзәгенә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында бу Административ регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган белешмәләрне үз эченә ала.

1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы (алга таба – РФ ХК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында” 19 апрель, 1991 ел, № 1032-1 Россия Федерациясе законы (алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон) (РСФСРның Халык депутатлары съезды һәм РСФСР Югары Советы хәбәрләре, 1991, № 18, 566 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 181-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында”

27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Персональ мәгълүматлар турында" 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Вәкаләтләр бүлешүне камилләштерүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 29 декабрь, 2006 ел, № 258-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 1, 21 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 07.05.2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Хезмәт һәм мәшгульлек федераль хезмәте хакында нигезләмәне раслау турында" 2004 елның 30 июнендәге № 324 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 28, 2901 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Кулай эш эзләү максатларында гражданнарны теркәү, эшсез гражданнарны теркәү тәртибе һәм кулай эшне сайлауга таләпләр турында" 2012 елның 7 сентябрендәге № 891 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 38, 5103 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Персональ мәгълүматларны персональ мәгълүмат системаларында эшкәрткәндә, аларны саклауга таләпләрне раслау турында" 2012 елның 1 ноябрендәге № 1119 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 45, 6257 ст.);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2005 елның 29 июлендәге "Халык мәшгульлегенә булышу һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында" № 485 боерыгы белән расланган Халык мәшгульлегенә булышу һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе хакындагы нигезләмә (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2005, № 39, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 8 октябрендәге "Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучыларның (физик затлар һәм эш бирүчеләрнең) регистрларын алып бару тәртибе турында (аларда мәгълүмат күрсәтүнең тәртибен, срокларын һәм формасын кертеп)" № 972н боерыгы (Российская газета, 2011, 2 февраль);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 26 февралендәге “Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучының “личное дело”сы бланклары формасын раслау турында” № 125н боерыгы (алга таба – № 125н боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 7 мартындагы “Мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында” № 92н боерыгы белән расланган Мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандарты (алга таба – № 92н Стандарт) (Российская газета, 2013, 28 май);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчкәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашканда финанс ярдәме бирү тәртибен раслау турында” 15.06.2012 № 515 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчкәндә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашканда финанс ярдәме бирү тәртибе (алга таба – № 515 Тәртип) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2012, № 47, 1605 ст.);

1.9. Бу Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Бу Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте (№ 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункты) күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның формасы 2015 елның 26 февралендәге № 125н боерыгы белән расланды.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Татарстан Республикасы халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү. | Халык мәшгульлеге турындагы № 1032-1 законның 7.1-1 ст. 1 өл. 8 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасының Халык мәшгульлеге хезмәте дәүләт учреждениесе (алга таба – халык мәшгульлеге үзәге).<br>Халык мәшгульлеге үзәге Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт хезмәте күрсәтүне башкара. | № 92н Стандартның 4 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып, эшсез гражданинга башка җирлектә эшкә урнашу өчен 26.02.2015 № 125н боерыкка 8 нче кушымта нигезендәге форма буенча эшкә юллама бирү тора;<br>халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга бер урыннан икенче урынга күчкәндә яки эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашканда финанс ярдәме бирү яисә аны бирүдән сәбәпләрен аңлатып баш тарту. | № 92н Стандартның 20 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; | Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителгән максималь вакыты, бер урыннан икенче урынга күчү турында килешү (күчеп урнашу турында килешү) төзү, шулай ук эшсез гражданинга (эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына) финанс ярдәменең күләмен билгеләү һәм аны банкта яки бүтән | №92н Стандартның 19 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | кредит оешмасында ачылган лицевой счетка (исәп-хисап счетына) күчерү өчен кирәкле вакытны кертмичә, 30 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Халык мәшгульлеге үзәгенә мөрәҗәгать итүнең көнен һәм вакытын эшсез гражданин белән килештерү, Интернет челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә, почта элемтәсе чараларын кулланып, гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча башкарыла. Эшсез гражданинның мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын алдан килештергән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Эшсез гражданин КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны КФҮ һәм халык мәшгульлеге үзәге арасында хезмәттәшлек итү турындагы килешү белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча, халык мәшгульлеге үзәгенә тапшыру тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган. | № 92н Стандартның 8 п.;<br><br>№ 92н Стандартның 9 п.; |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу | 1.1. Халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында 26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 37 нче кушымта нигезендәге гариза (алга таба – гариза) яки халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күчүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында халык мәшгульлеге үзәге белгече тарафыннан бирелгән тәкъдим, һәм дәүләт хезмәте алучының халык мәшгульлеге үзәге | № 92н Стандартның 5 п. |

| | | |
|---|---|---|
| ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | белгече тәкъдименә 26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 38 нче кушымта нигезендәге ризалыгы.<br>1.2. Эшсез гражданин, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ; чит ил гражданинының, гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документ) күрсәтә.<br>1.3. Инвалидлар категориясенә караучы дәүләт хезмәте алучылар, өстәмә рәвештә, инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасын яисә инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең билгеләнгән тәртиптә бирелүче һәм хезмәтнең киңәш ителүче рәвеше һәм шартлары турында бәяләмәне үз эченә алучы индивидуаль программасын тапшыра.<br>1.4. Гаилә әгъзалары булган эшсез гражданин, эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте алу өчен, өстәмә рәвештә тапшыра:<br>аның гаиләсе әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар – аның гаиләсенең чит ил гражданины булып торучы әгъзасы өчен, гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документ – аның гаиләсенең гражданлыксыз зат булып торучы әгъзасы өчен) Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган күчермәләрен;<br>эшсез гражданинның гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар) (ирекле формада):<br>аларның персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуны;<br>персональ мәгълүматларын халык мәшгульлеге үзәгенә тапшырганда, эшсез гражданинның алар исеменнән эш йөртергә вәкаләтен. | № 92н Стандартның 14 п.;<br>№ 92н Стандартның 15 п.<br><br>№ 92н Стандартның 15 п.<br><br>№ 210-ФЗ Федераль Законның 7 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм халык мәшгульлеге үзәге белгече тарафыннан раслана.<br>Эшсез гражданин тарафыннан тапшырылучы документта хәләл җефетләрнең икенчесенең аның персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуны дәлилләүче имзасы халык мәшгульлеге үзәге белгече тарафыннан Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган булырга тиеш.<br>1.5. Халык мәшгульлеге үзәге белгече тарафыннан эшсез гражданинга халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчкәндә (күчеп урнашканда) финанс ярдәмен билгеләү һәм күчерү турында карар кабул ителсен өчен, эшсез гражданин № 515 Тәртипкә 1 – 4 кушымталар нигезендәге форма буенча, түбәндәге документларны өстәп, гариза бирә:<br>1.5.1. вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчкәндә:<br>1.5.1.1. эш бирүче белән төзелгән хезмәт килешүенең эш бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарына туры китереп билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсен;<br>1.5.1.2. хезмәт кенәгәсенең эш бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган, эшкә кабул итү һәм хезмәт килешүе яки күчену турындагы килешү срогы чыгуга бәйле рәвештә эштән азат итү турындагы язмасы булган күчермәсен (төп нөсхәсе күрсәтелмәгән очракта);<br>1.5.1.3. башка җирлектә эшләү вакытында эш урынына бару һәм кире кайту бәясен түләү буенча транспорт чыгымнары, торактан вакытлыча файдалануга түләү чыгымнары турындагы мәгълүматларны раслаучы документларның төп нөсхәләрен;<br>1.5.1.4. исәп-хисап счеты күрсәтелгән документ күчермәсен; | № 515 Тәртипнең 2.1.5 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | 1.5.2. эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына башка җирлеккә күченгәндә:<br>1.5.2.1. эш бирүче белән төзелгән хезмәт килешүенең эш бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарына туры китереп билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсен;<br>1.5.2.2. эшсез гражданинның һәм аның гаилә әгъзаларының күченү буенча транспорт чыгымнары һәм йорттагы мөлкәтне элекке яшәү урыныннан яңа яшәү урынына транспортта алып бару бәясен түләү буенча чыгымнар турындагы мәгълүматларны раслаучы документларның (квитанцияләр, касса чеклары, счет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары, килешүләр һ.б.) төп нөсхәләрен;<br>1.5.2.3. эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсен;<br>1.5.2.4. эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесләрен таныклаучы документлар күчермәләрен;<br>1.5.2.5. персональ мәгълүматларын тапшырганда, гаилә әгъзалары яки аларның законлы вәкилләре исеменнән эш йөртергә эшсез гражданинның вәкаләтен раслаучы документны;<br>1.5.2.6. исәп-хисап счеты күрсәтелгән документ күчермәсен.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, документларның аңа кушып җибәрелүче күчермәләре, паспорт күчермәсен яки аны алмаштыручы документ күчермәсен дә кертеп, Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучының вәкиле, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документларның күчермәләрен тапшыра.<br>Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп | № 515 Тәртипнең 2.2.5 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырыла һәм халык мәшгульлеге үзәге белгече тарафыннанраслана. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алыналар:<br>- эшсез гражданинның 14 яшькә җитмәгән гаилә әгъзалары тууны дәүләт теркәве турында мәгълүматлар[1] (ЗАГС органнарыннан);<br>- гаилә составы турында мәгълүматлар (гражданнарның вакытлыча булу һәм яшәү урыннарында теркәү исәбен алып баруга вәкаләтле оешмалардан).<br>Эшсез гражданин 14 яшькә җитмәгән гаилә әгъзаларының туу турында таныклыклары күчермәсен, аның төп нөсхәсен күрсәтеп, яки аның нотариуста раслатылган күчермәсен, гаилә составы турындагы белешмәне тапшырырга хокуклы, мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.<br>Эшсез гражданинның югарыда күрсәтеп үтелгән мәгълүматлар кергән документларны тапшырмавы эшсез гражданинга хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый. | № 92н Стандартның 15 п. |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне килештерү таләп ителми. | |

[1] Алга таба – туу турында таныклык.

| | | |
|---|---|---|
| башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр күздә тотылмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр күздә тотылмаган.<br>Халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, бер урыннан икенче урынга баруда булышлык итү өлешендә эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>1) документлар белән бу Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>2) түбәндәгеләрнең булмавы:<br>- гариза яки эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында халык мәшгульлеге үзәге белгеченең тәкъдименә ризалыгы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документлар (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең билгеләнгән тәртиптә бирелүче индивидуаль программасы | № 92н Стандартның 11 п.;<br>№ 92н Стандартның 14 п.;<br>№ 92н Стандартның 15 п.;<br>№ 515 Тәртипнең 2.1.5, 2.1.6, 2.1.7, 2.2.5 п.п. |

| | | |
|---|---|---|
| | (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);<br>3) гаризага кушып бирелүче, почта белән килгән документларны Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган килеш тапшыру.<br>Халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү өлешендә эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>1) документлар белән бу Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>2) түбәндәгеләрнең булмавы:<br>- гариза яки эшсез гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турында халык мәшгульлеге үзәге белгеченең тәкъдименә ризалыгы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документлар (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең билгеләнгән тәртиптә бирелүче индивидуаль программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);<br>- эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар (чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар – чит ил гражданины булып торучы гариза бирүченең гаилә әгъзасы өчен; гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документ – гражданлыксыз зат булып торучы гариза бирүченең гаилә әгъзасы өчен ); | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) гаризага кушып бирелүче, почта белән килгән документларны Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган килеш тапшыру.<br>Халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, бер урыннан икенче урынга күчкәндә яки башка җирлеккә күчеп урнашканда, эшсез гражданинга финанс ярдәме бирүдән баш тарту өчен нигез булып, тиңдәшле рәвештә, күчену турындагы килешүнең яки күчеп урнашу турындагы килешүнең булмавы, № 515 Тәртипнең 1 – 4 нче кушымталары нигезендәге форма буенча гаризаны агымдагы елның 25 декабренә кадәр тапшырмау тора. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | № 210-ФЗ Федераль законның 8 ст.;<br>Халык мәшгульлеге турында № 1032-1 законның 15 ст. 3 п;<br>№ 92н Стандартның 13 п. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең | Эшсез гражданин халык мәшгульлеге үзәгенә шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте чират буенча күрсәтелә. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, чиратта көтү вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Көнен һәм вакытын алдан килештергән очракта, дәүләт хезмәте | № 92н Стандартның 7 п.;<br>№ 601 Указның 1 п.;<br>№ 92н Стандартның |

| | | |
|---|---|---|
| максималь срогы | күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артырга тиеш түгел. | 8 п. |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы | Гариза кергән көнне.<br>Гаризаны теркәү дигәндә, халык мәшгульлеге үзәгенең, исәпкә алу язуының теркәү номерын биреп, эшсез гражданин тапшырган документларда булган мәгълүматларны Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучыларның (физик затлар һәм эш бирүчеләрнең) электрон регистрына (алга таба – Дәүләт хезмәте алучылар регистры) кертүе күздә тотыла. бирүчеләргә гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: ХМҮгә яки КФҮгә, ерактагы эш урынына шәхсән, почта элемтәсе аша, факсимиль элемтә чараларын кулланып яки электрон рәвештә, шул исәптән Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын файдаланып мөрәҗәгать итеп.<br>Эшсез гражданинның рәсми мөрәҗәгате буенча, гаризаның гаризаны кабул итү көне һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында мәгълүматы булган күчермәсе бирелергә мөмкин. | Халык мәшгульлеге турындагы законның 16.1 ст.<br>2 п. |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясе инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында | Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле офис җиһазлары, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керүе һәм алардан чыгуы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә керү һәм аннан чыгу урыннары автоном өзлексез ток чыганагы булган, тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү | № 92н Стандартның 10 п. |

| | | |
|---|---|---|
| визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | урыннарында җәмәгатьчелек файдалана ала торган урыннар (бәдрәфләр) һәм килүчеләрнең өс киемнәрен саклау урыннары булдыру күздә тотыла.<br>Халык мәшгульлеге үзәге белгеченең эш урыны стенага эленгән мәгълүмат тактасы яки өстәл өстенә куелган, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән табличка белән җиһазландырыла.<br>Халык мәшгульлеге үзәге белгечләре күкрәккә тагыла торган, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси карточкалар (бейджлар) белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат дәүләт хезмәте алучылар өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, шулай ук Интернет-ресурсларда (Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында) урнаштырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында текстлы һәм мультимедиаль мәгълүматны рәсмиләштерү гражданнарның бу мәгълүматны күреп һәм ишетеп, уңайлы рәвештә кабул итүенә туры килергә тиеш. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен КФҮдә, ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>1. Шәхси яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә эшсез гражданин өчен дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар рәсмиләштерү үрнәкләре турындагы мәгълүматны алу мөмкинлеге (шәхсән кабул итү вакытында, телефон элемтәсе чараларын, электрон почтаны файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүматлы материаллар (брошюралар, памяткалар, буклетлар һ.б.) нәшер итү, мәгълүматны Татарстан Республикасы порталына | № 880 ТР МК карарының 2.4 п.;<br>№ 601 Указның 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | урнаштыру ярдәмендә).<br>2. Эшсез гражданинның гаризалар формаларыннан һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка документлардан файдалана алу мөмкинлеген, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеген дә тәэмин итү.<br>3. Инвалидларга аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү.<br>4. Гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты саклану.<br>5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсен, электрон почтаны файдаланып, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, КФҮ аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтыннан.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, халык мәшгульлеге үзәге тарафыннан Россия Федерациясенең халык мәшгульлеге турындагы законының мәҗбүри таләпләре, бу Административ регламентның нигезләмәләре үтәлү.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары үтәлү.<br>3. Бу Административ регламент белән билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге үтәлү.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуларның нигезлелеге.<br>5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Эшсез гражданинның халык мәшгульлеге үзәге белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә турыдан-туры – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә | |

| | | |
|---|---|---|
| | алмыйча);<br>документларны почта аша, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәргәндә – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең ХМҮ белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте КФҮ, ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.<br>Эшсез гражданин КФҮгә, ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны ХМҮгә тапшыру гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, халык мәшгульлеге үзәге һәм КФҮ хезмәттәшлегенең тәртибе халык мәшгульлеге үзәге һәм КФҮ арасында хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлегенең тәртибе КФҮ эше регламенты белән җайга салына.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, эшсез гражданнарга эш бирүче белән телефон яки Интернет челтәреннән файдаланып, видеоэлемтә ярдәмендә әңгәмәләр үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны эшсез гражданин http://mtsz@tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алырга мөмкин. | № 92н Стандартның 9 п.<br><br>№ 92н Стандартның 23 п. |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүдән гайре электрон рәвештә күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында алар турында мәгълүматлар булган эшсез гражданнарга, телефон элемтәсе яки электрон элемтә чараларыннан файдаланып, вакытлыча эшкә урнашу өчен буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булу-булмау | № 92н Стандартның 6 п.;<br>№ 92н Стандартның 22 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | турында, өч көн эчендә халык мәшгульлеге үзәгенә килү тәкъдиме белән, эш бирүчедән белешмәләр керү хакындагы мәгълүматны алу мөмкинлеге тәэмин итеплә, эшсез гражданинның һөнәри әзерлеге хезмәт вазыйфасын үтәүгә карата эш бирүченең таләпләренә тәңгәл килүе шарты белән. | |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Халык мәшгульлеге үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү үз эченә ала:

вакытлыча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга икенче җирлеккә күчүдә булышлык итүне (алга таба – эшкә урнашу өчен, икенче җирлеккә күчүдә булышлык итү);

эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә яңа яшәү урынына күчеп урнашуда булышлык итүне (алга таба – эшкә урнашу өчен икенче җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү).

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.2.1. Вакытлыча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга икенче җирлеккә күчүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

1) эшсез гражданинга консультация бирү, эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган мәгълүматларны анализлау;

3) эшсез гражданинга түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булу;

хезмәтнең рәвеше, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә куела торган квалификация таләпләре, бу оешмаларның хезмәткәрләренә бирелүче ташламалар турында;

башка җирлектәге эш урынында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге;

халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә бирелә торган финанс ярдәме күләме, аны бирү һәм кайтарып алу тәртибе һәм шартлары;

4) башка җирлектәге эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрыннан өземтә бирү;

5) эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү;

6) эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү;

7) эшсез гражданинга башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү;

8) эшсез гражданин белән күченү турында килешү төзү;

9) эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында яки эшсез гражданинга финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

10) эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәмен билгеләү;

11) эшсез гражданинга финанс ярдәмен күчерү;

12) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү.

3.2.2. Эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә яңа яшәү урынына күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

1) эшсез гражданинга консультация бирү, эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган мәгълүматларны анализлау;

3) мәгълүматлар алу өчен ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр әзерләү;

4) эшсез гражданинга түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булу;

хезмәтнең рәвеше, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә куела торган квалификация таләпләре, бу оешмаларның хезмәткәрләренә бирелүче ташламалар турында;

башка җирлектәге эш урынында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге;

эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә яңа яшәү урынына күчеп урнашканда бирелә торган финанс ярдәме күләме, аны бирү һәм кайтарып алу тәртибе һәм шартлары;

5) башка җирлектәге эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрыннан өземтә бирү;

6) эшсез гражданин белән эш вариантларын килештерү;

7) эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү;

8) эшсез гражданинга башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү;

9) эшсез гражданин белән күчеп урнашу турында килешү төзү;

10) эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында яки эшсез гражданинга финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

11) эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәмен билгеләү;

12) эшсез гражданинга финанс ярдәмен ул кредит оешмасында ачкан лицевой счетка күчерү.

3.2.3. Эшсез гражданинга дәүләт хезмәтен электрон рәвештә, КФҮ, ерактагы эш урыны аша күрсәтү.

3.2.4. Техник хатаны (ялгыш язуны, басмадагы ялгышлыкны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемалары

3.3.1. Вакытлыча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга башка җирлеккә күчүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр

эзлеклелегенең блок-схемасы бу Административ регламентка 2 нче кушымтада бирелә.

3.3.2. Эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә яңа яшәү урынына күчеп урнашканда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Административ регламентка 3 нче кушымтада бирелә.

3.3.3. Техник хатаны төзәтү блок-схемасы бу Административ регламентка 4 нче кушымтада бирелә.

3.4. Вакытлыча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга башка җирлеккә күчүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен бу Административ регламент белән күздә тотылган административ гамәлләрнең үтәлеше

3.4.1. Эшсез гражданинга консультация бирү, эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Эшсез гражданин, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен, халык мәшгульлеге үзәгенә телдән (шәхсән үзе яки телефоннан) яисә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итә.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан һәм эшсез гражданинга ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Эшсез гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга теләгән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга язмача консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан.

Үтәлү срогы: процедура эшсез гражданин мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация бирү, эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.4.2. Эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган мәгълүматларны анализлау.

3.4.2.1. Эшсез гражданин халык мәшгульлеге үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 37 нче кушымта нигезендәге гариза (алга таба – гариза) һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3 пунктчалары белән билгеләнгән документлар белән мөрәҗәгать иткәндә.

Эшсез гражданинның гаризасы халык мәшгульлеге үзәгенә почта аша, факсимиль элемтә ярдәмендә яки электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яки гаризаны КФҮдән, ерактагы эш урыныннан тапшыру ярдәмендә кергән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече гариза кергән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча, гражданин белән шәхсән кабул итү көнен, вакытын килештерә.

Шәхсән кабул итү барышында халык мәшгульлеге үзәге белгече:

бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3 пунктчалары белән күздә тотылган документлар булуны тикшерә;

Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алган программ-техник комплекска дәүләт хезмәтләре алучы турындагы мәгълүматларны эзләү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

эшсез гражданинның гаризасы халык мәшгульлеге үзәгендә эшсез гражданин сыйфатында исәптә тору-тормавын, эшсез гражданинның инвалидлар категориясенә карау-карамавын билгели (халык мәшгульлеге үзәге белгеченең тәкъдиме һәм эшсез гражданинның халык мәшгульлеге үзәге белгеченең тәкъдименә ризалыгы булган очраклардан гайре);

халык мәшгульлеге үзәгенең агымдагы архивыннан эшсез гражданинның "личное дело"сын ала (булган очракта).

Бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3 пунктчаларында күрсәтелгән документлар һәм халык мәшгульлеге үзәге карамагында булган белешмәләр нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында бу Административ регламентка 5 нче кушымта нигезендәге форма буенча язмача карар рәсмиләштерә, баш тартуның сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата һәм эшсез гражданинны бу карар белән таныштырып, кул куйдыра.

Эшсез гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән кул куйдырып таныштырылмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында аның адресына язмача хәбәрнамә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече, бу Административ регламентка туры китереп, эшсез гражданин белән эшен дәвам иттерә.

Үтәлү срогы: процедура 2 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү, шәхсән кабул итүгә чакыру (гариза җибәрелгән очракта), дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, баш тарту турында язмача хәбәр җибәрү.

3.4.2.2. Халык мәшгульлеге үзәге белгеченең эшсез гражданинга эшкә урнашу өчен, башка җирлеккә күчүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдиме (алга таба – халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдиме).

Халык мәшгульлеге үзәгенең эшсез гражданнарны теркәү исәбен алып баручы белгече, эшсез гражданин кулай эш сайлау өчен халык мәшгульлеге үзәгенә килгәндә:

бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3 пунктчалары белән күздә тотылган документлар булуны тикшерә;

Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алган программ-техник

комплекста дәүләт хезмәтләре алучы турындагы мәгълүматларны эзләү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

халык мәшгульлеге үзәгенең агымдагы архивыннан эшсез гражданинның “личное дело”сын ала (булган очракта);

26.02.2015 ел, № 125н боерык белән расланган форма нигезендә (38 нче кушымта) дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим рәсмиләштерү юлы белән, дәүләт хезмәте күрсәтергә тәкъдим итә.

Эшсез гражданин ризалашкан очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече, бу Административ регламентка туры китереп, эшсез гражданин белән эшен дәвам иттерә.

Үтәлү срогы: процедура 2 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим рәсмиләштерү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә ризалык (баш тарту) алу.

3.4.3. Эшсез гражданинга вакансияләр һәм буш эш урыннары булу (булмау), финанс ярдәменең күләме, аны бирүнең тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга түбәндәге мәгълүматны бирә:

башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булу турында;

хезмәтнең рәвеше, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә куела торган квалификация таләпләре, бу оешмаларның хезмәткәрләренә бирелүче ташламалар турында;

башка җирлектәге эш урынында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге;

халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә бирелә торган финанс ярдәме күләме, аны бирүнең һәм кайтарып алуның тәртибе һәм шартлары турында.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинга вакансияләр һәм буш эш урыннары булу (булмау), финанс ярдәменең күләме, аны бирүнең тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

3.4.4. Башка җирлектәге эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрыннан өземтә бирү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече, буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган мәгълүматларга таянып, һөнәрне (белгечлекне), вазыйфа, эшчәнлек төре, һөнәри әзерлек дәрәҗәсе һәм квалификация, тәҗрибә һәм эш күнекмәләрен, ахыргы эш урынындагы хезмәт хакы күләмен, хезмәтнең ярамый торган һәм рөхсәт ителгән шартлары һәм төрләре турында киңәшләрне, эшсез гражданинның эзләнүче эшкә карата теләкләрен (хезмәт хакы, эш вакыты режимы, урнашкан урыны, хезмәтнең характеры, һөнәр (белгечлек)), шулай ук хезмәт функциясен үтәүгә һәм хезмәткәрнең кандидатурасына карата эш бирүченең таләпләрен исәпкә алып,

эшсез гражданинга башка җирлектә эш вариантларын сайлый.

Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында кулай эш вариантлары булган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлары булган исемлекне кәгазьгә бастырып чыгара һәм аны эшсез гражданинга тәкъдим итә.

Башка җирлектә эшсез гражданинга яраклы эш вариантлары булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә һәм, башка җирлектә эш вариантларын эзләү өчен, эшсез гражданинны халык мәшгульлеге үзәгенә кабат килергә чакыра.

Эш бирүчедән буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булу турында мәгълүматлар кергәч, эшсез гражданинның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүченең таләпләренә туры килү шарты белән, аның турында мәгълүматлар Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган эшсез гражданинга телдән (телефоннан) яки язмача (электрон документ рәвешендә) өч көн эчендә, эшкә юллама рәсмиләштерү һәм кулына бирү өчен, халык мәшгульлеге үзәгенә килергә тәкъдим ителә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлары булган исемлек, яисә халык мәшгульлеге үзәгенә кабат килергә чакыру.

3.4.5. Эш вариантларын эшсез гражданин белән килештерү.

Эшсез гражданин халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән башка җирлектә эш вариантын сайлый. Эшсез гражданин башка җирлектән берничә эш вариантын сайларга хокуклы.

Эшсез гражданин башка җирлектән эш вариантын сайламаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече сәбәпләрен ачыклый, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 1 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинның халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән эш вариантын сайлавы яки тәкъдим ителгән эш вариантларыннан баш тартуы, нәтиҗәләрне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү.

3.4.6. Эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү.

Башка җирлектән эшсез гражданин сайлаган эш вариантлары нигезендә, эшкә урнашуга җибәрү максатыннан, халык мәшгульлеге үзәге белгече телефоннан яисә электрон почта аша, вакансия булуны һәм эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эшсез гражданинга телефон элемтәсе яки, Интернет челтәреннән файдаланып, видеоэлемтә ярдәмендә әңгәмә уздыру мөмкинлеге тәэмин ителә.

Эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештермәгәндә, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга, бу Административ регламентның 3.4.4 – 3.4.5 пунктлары белән күздә тотылган гамәлләр эзлеклелегенә туры китереп,

башка җирлектә эш вариантларын сайлауны дәвам иттерергә тәкъдим итә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү, телефон элемтәсе яки, Интернет челтәреннән файдаланып, видеоэлемтә ярдәмендә әңгәмә уздыру.

3.4.7. Башка җирлектә эшкә урнашу өчен, күчкәндә, эшсез гражданинга юллама бирү.

Эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештергәндә, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга 26.02.2015, № 125н боерыкка 8 нче кушымта нигезендәге форма буенча эшкә юллама рәсмиләштерә һәм кулына бирә, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 1 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшкә юллама рәсмиләштерү һәм эшсез гражданин кулына бирү.

3.4.8. Эшсез гражданин белән икенче урынга күчү турында килешү төзү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга, халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча икенче урынга күчкәндә финанс ярдәме бирү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирә һәм эшсез гражданин белән эшкә урнашу өчен икенче урынга күчүдә булышу турында килешү (алга таба – күчү турында килешү) төзи.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 15 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: күчү турында килешү.

3.4.9. Эшсез гражданинга, күченгәндә, финанс ярдәме бирү турында яки эшсез гражданинга финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итү.

Эшсез гражданин белән икенче урынга күчү турында килешү төзелгән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирелү турында карар кабул итә.

Финанс ярдәме бирелү турындагы карарны халык мәшгульлеге үзәге белгече бу Административ регламентка 7 нче кушымта нигезендәге форма буенча рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән таныштырып, кул куйдыра.

Күчү турында килешү булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында бу Административ регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча карар рәсмиләштерә, баш тартуның сәбәпләрен, нигезләрен, финанс ярдәме бирелү тәртибен аңлата һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән таныштырып, кул куйдыра.

Эшсез гражданин финанс ярдәме бирү турындагы яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турындагы карар белән кул куйдырып таныштырылмаган очракта, кабул ителгән карар хакында аның адресына язмача хәбәрнамә җибәрелә.

Үтәлү срогы: процедура эшсез гражданиннан бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5 пунктчасы белән күздә тотылган гариза кергән моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: финанс ярдәме бирү турындагы яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турындагы карарны рәсмиләштерү, эшсез гражданинны карар белән таныштырып, кул куйдыру яисә кабул ителгән карар хакында эшсез гражданинга язмача хәбәрнамә җибәрү.

3.4.10. Икенче урынга күчкәндә, эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәмен билгеләү.

Эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәме эшсез гражданин гариза һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.1.1 – 1.5.1.4 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшыргач билгеләнә.

Халык мәшгульлеге үзәгенә электрон документлар рәвешендә җибәрелгән документлар һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ һәм № 210-ФЗ Федераль законнар таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган (расланган) булырга тиеш.

Гаризаны, бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.1.1 – 1.5.1.4 пунктчалары белән күздә тотылган документларны кушып, тапшыру турындагы хәбәрнамә белән заказлы хат итеп җибәргән очракта, финанс ярдәмен билгеләү турындагы гаризага эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документның нотариуста расланган күчермәсе өстәлә.

Бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.1.1 – 1.5.1.4 пунктчаларында күрсәтелгән тапшырылган документлар нигезендә, халык мәшгульлеге үзәге белгече Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына эшсез гражданин турындагы мәгълүматларны эзләү параметрларын кертә һәм эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турында яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Эшкә урнашу өчен, башка җирлеккә күчкәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме билгеләү һәм аның күләме турында бу Административ регламентның 8 нче кушымтасына туры китереп, боерык проектын әзерли, аны халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесенә имзалауга тапшыра, шулай ук әлеге боерык белән эшсез гражданинны кул куйдырып таныштыра.

Эшкә урнашу өчен, башка җирлеккә күчкәндә эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәмен түләүдән баш тарту турында бу Административ регламентның 9 нчы кушымтасы нигезендәге форма буенча, боерык проектын әзерли, аны халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесенә имзалауга тапшыра, шулай ук әлеге боерык белән эшсез гражданинны кул куйдырып таныштыра.

Эшсез гражданин башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәмен түләү рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән кул куйдырып таныштырылмаган очракта, финанс ярдәмен түләүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында аның адресына язмача хәбәрнамә җибәрелә.

Бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5.1.1 – 1.5.1.4 пунктчаларында күрсәтелгән эшсез гражданин тапшырган документларда булган мәгълүматларны халык мәшгульлеге үзәге белгече Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура эшсез гражданин гариза һәм документларны биргән моменттан башлап 5 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләү турындагы боерык яки эшсез гражданинга финанс ярдәмен түләү рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы боерык, эшсез гражданинны боерыклар белән таныштырып, кул куйдыру яисә финанс ярдәме билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) эшсез гражданинга язмача хәбәрнамә җибәрү.

3.4.11. Икенче урынга күчкәндә, эшсез гражданинга финанс ярдәмен күчерү.

Эшсез гражданинга финанс ярдәме билгеләү турындагы боерык нигезендә, халык мәшгульлеге үзәге белгече, эш көннәрендә исәпләнүче 10 көнлек срок эчендә, халык мәшгульлеге үзәге счетына акча килгәннән соң, килгән акчаны эшсез гражданинның лицевой (банк) счетына һәм (яки) эшсез гражданин № 515 Тәртипкә 1 – 3 нче кушымталар нигезендәге форма буенча тутырылган гаризасында күрсәткән бүтән исәп-хисап счетларына күчерә.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече түләү документларында булган мәгълүматларны Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 5 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: акча күчерү.

3.4.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

эшсез гражданинга башка җирлектә эшкә урнашу өчен 26.02.2015, № 125н боерыкка 8 нче кушымта нигезендәге форма буенча эшкә юллама бирү;

халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме күрсәтү яисә аны күрсәтүдән дәлилле баш тарту.

3.4.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен (бу Административ регламентның 3.4.4, 3.4.7, 3.4.10 пунктлары белән күздә тотылган процедураларның берсе тәмамлангач, аерым административ гамәлләрне үтәү нәтиҗәләрен) Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура бу Административ регламентның 3.4.4, 3.4.7, 3.4.10 пунктлары белән күздә тотылган процедураларның берсе тәмамланган моменттан башлап 2 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен (административ гамәлне үтәү нәтиҗәләрен) Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү.

3.5. Эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына

башка җирлеккә яңа яшәү урынына күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, бу Административ регламент беләи күздә тотылган административ гамәлләрне башкару.

3.5.1. Эшсез гражданинга консультация бирү, эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Эшсез гражданин, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен, халык мәшгульлеге үзәгенә телдән (шәхсән үзе яки телефоннан) яисә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итә.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан һәм эшсез гражданинга ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Эшсез гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга теләгән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга язмача консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан.

Үтәлү срогы: процедура эшсез гражданин мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация бирү, эшсез гражданинга ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.5.2. Эшсез гражданин тапшырган документларда һәм Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган мәгълүматларны анализлау.

3.5.2.1. Эшсез гражданин халык мәшгульлеге үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 26.02.2015 ел, № 125н боерык белән расланган форма буенча (37 нче кушымта) гариза (алга таба – гариза) һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3, 1.4 пунктчалары белән билгеләнгән документлар белән мөрәҗәгать иткәндә.

Эшсез гражданинның гаризасы халык мәшгульлеге үзәгенә почта аша, факсимиль элемтә ярдәмендә яки электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яки гаризаны КФҮдән, ерактагы эш урыныннан тапшыру ярдәмендә кергән очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече гариза кергән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча, гражданин белән шәхсән кабул итү көнен, вакытын килештерә.

Шәхсән кабул итү барышында халык мәшгульлеге үзәге белгече:

бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3, 1.4 пунктчалары белән күздә тотылган документлар булуны тикшерә;

Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алган программ-техник комплекска дәүләт хезмәтләре алучы турындагы мәгълүматларны эзләү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

эшсез гражданинның гаризасы халык мәшгульлеге үзәгендә эшсез гражданин сыйфатында исәптә тору-тормавын, эшсез гражданинның инвалидлар категориясенә карау-карамавын билгели (халык мәшгульлеге үзәге белгеченең

тәкъдиме һәм эшсез гражданинның халык мәшгульлеге үзәге белгеченең тәкъдименә ризалыгы булган очраклардан гайре);

халык мәшгульлеге үзәгенең агымдагы архивыннан эшсез гражданинның “личное дело”сын ала (булган очракта).

Бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3, 1.4 пунктчаларында күрсәтелгән документлар һәм халык мәшгульлеге үзәге карамагында булган белешмәләр нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында бу Административ регламентка 5 нче кушымта нигезендәге форма буенча язмача карар рәсмиләштерә, баш тартуның сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата һәм эшсез гражданинны бу карар белән таныштырып, кул куйдыра.

Эшсез гражданин дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән кул куйдырып таныштырылмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында аның адресына язмача хәбәрнамә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече, бу Административ регламентка туры китереп, эшсез гражданин белән эшен дәвам иттерә.

Үтәлү срогы: процедура 2 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү, шәхсән кабул итүгә чакыру (гариза җибәрелгән очракта), дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карар, баш тарту турында язмача хәбәр җибәрү.

3.5.2.2. Халык мәшгульлеге үзәге белгеченең эшсез гражданинга халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, башка җирлеккә күчеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдиме (алга таба – халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдиме).

Халык мәшгульлеге үзәгенең эшсез гражданнарны теркәү исәбен алып баручы белгече, эшсез гражданин кулай эш сайлау өчен халык мәшгульлеге үзәгенә килгәндә:

бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.2, 1.3, 1.4 пунктчалары белән күздә тотылган документлар булуны тикшерә;

Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрын үз эченә алган программ-техник комплекска дәүләт хезмәтләре алучы турындагы мәгълүматларны эзләү параметрларын кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

халык мәшгульлеге үзәгенең агымдагы архивыннан эшсез гражданинның “личное дело”сын ала (булган очракта);

26.02.2015 ел, № 125н боерык белән расланган форма нигезендә (38 нче кушымта) дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим рәсмиләштерү юлы белән,

дәүләт хезмәте күрсәтергә тәкъдим итә.

Эшсез гражданин ризалашкан очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече, бу Административ регламентка туры китереп, эшсез гражданин белән эшен дәвам иттерә.

Үтәлү срогы: процедура 2 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим рәсмиләштерү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә ризалык (баш тарту) алу.

3.5.3. Мәгълүматлар алу өчен ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр рәсмиләштерү.

3.5.3.1. Тапшырылган документлар составында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, бу Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин аларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, соралучы мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органнарына тиешле рәсми мөрәҗәгать (рәсми мөрәҗәгатьләр) җибәрә:

- эшсез гражданинның 14 яшькә җитмәгән гаилә әгъзалары тууны дәүләт теркәве турында мәгълүматлар (ЗАГС органнарына);

- гаилә составы турында мәгълүматлар (гражданнарның вакытлыча булу һәм яшәү урыннарында теркәү исәбен алып баруга вәкаләтле оешмаларга).

3.5.3.2. Соралучы мәгълүматлар алар карамагында булган дәүләт органнарына рәсми мөрәҗәгать кергән моменттан алып ике көн эчендә ведомствоара хезмәттәшлек органы белгече халык мәшгульлеге үзәгенә мәгълүматлар бирә.

Үтәлү срогы: процедуралар гариза кергән яки халык мәшгульлеге үзәге белгеченең тәкъдиме ясалган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирүне сорап, рәсми мөрәҗәгатьләр, электрон рәвештә алынган мәгълүматлар.

3.5.4. Эшсез гражданинга вакансияләр булу (булмау), финанс ярдәменең күләме, аны бирүнең тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга телдән мәгълүмат бирә:

башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булу турында;

хезмәтнең рәвеше, режимы, шартлары һәм хезмәткәргә куела торган квалификация таләпләре, бу оешмаларның хезмәткәрләренә бирелүче ташламалар турында;

башка җирлектәге эш урынында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге;

халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга икенче җирлеккә күчкәндә бирелә торган финанс ярдәме күләме, аны бирүнең һәм кайтарып алуның тәртибе һәм шартлары турында.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинга вакансияләр һәм буш эш урыннары булу (булмау), финанс ярдәменең күләме, аны бирүнең тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү.

3.5.5. Башка җирлектәге эш вариантларын сайлау яки башка җирлектә эш вариантлары булмау турында Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрыннан өземтә бирү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече, буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган мәгълүматларга таянып, һөнәрне (белгечлекне), вазыйфа, эшчәнлек төре, һөнәри әзерлек дәрәҗәсе һәм квалификация, тәҗрибә һәм эш күнекмәләрен, ахыргы эш урынындагы хезмәт хакы күләмен, хезмәтнең ярамый торган һәм рөхсәт ителгән шартлары һәм төрләре турында киңәшләрне, эшсез гражданинның эзләнүче эшкә карата теләкләрен (хезмәт хакы, эш вакыты режимы, урнашкан урыны, хезмәтнең характеры, һөнәр (белгечлек)), шулай ук хезмәт функциясен үтәүгә һәм хезмәткәрнең кандидатурасына карата эш бирүченең таләпләрен исәпкә алып, эшсез гражданинга башка җирлектә эш вариантларын сайлый.

Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында кулай эш вариантлары булган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлары булган исемлекне кәгазьгә бастырып чыгара һәм аны эшсез гражданинга тәкъдим итә.

Башка җирлектә эшсез гражданинга яраклы эш вариантлары булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә һәм, башка җирлектә эш вариантларын эзләү өчен, эшсез гражданинны халык мәшгульлеге үзәгенә кабат килергә чакыра.

Эш бирүчедән буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булу турында мәгълүматлар кергәч, эшсез гражданинның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүченең таләпләренә туры килү шарты белән, аның турында мәгълүматлар Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында булган эшсез гражданинга телдән (телефоннан) яки язмача (электрон документ рәвешендә) өч көн эчендә, эшкә юллама рәсмиләштерү һәм кулына бирү өчен, халык мәшгульлеге үзәгенә килергә тәкъдим ителә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлары булган исемлек, яисә халык мәшгульлеге үзәгенә кабат килергә чакыру.

3.5.6. Эш вариантларын эшсез гражданин белән килештерү.

Эшсез гражданин халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән башка җирлектә эш вариантын сайлый. Эшсез гражданин башка җирлектән берничә эш вариантын сайларга хокуклы.

Эшсез гражданин башка җирлектән эш вариантын сайламаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече сәбәпләрен ачыклый, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 1 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинның халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән эш вариантын сайлавы яки тәкъдим ителгән эш

вариантларыннан баш тартуы, нәтиҗәләрне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү.

3.5.7. Эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү.

Башка җирлектән эшсез гражданин сайлаган эш вариантлары нигезендә, эшкә урнашуга җибәрү максатыннан, халык мәшгульлеге үзәге белгече телефоннан яисә электрон почта аша, вакансия булуны һәм эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерә.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече эш бирүчегә халык мәшгульлеге үзәгенә эшсез гражданинны эшкә урнаштыру мөмкинлеген раслауны (киңәш ителүче форма бу Административ регламентка 10 нчы кушымтада китерелгән) эшсез гражданин кандидатурасын килештергән көнне тапшыру турында мәгълүмат бирә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эшсез гражданинга телефон элемтәсе яки, Интернет челтәреннән файдаланып, видеоэлемтә ярдәмендә әңгәмә уздыру мөмкинлеге тәэмин ителә.

Эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештермәгәндә, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга, бу Административ регламентның 3.5.5 – 3.5.6 пунктлары белән күздә тотылган гамәлләр эзлеклелегенә туры китереп, башка җирлектә эш вариантларын сайлауны дәвам иттерергә тәкъдим итә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештерү, телефон элемтәсе яки, Интернет челтәреннән файдаланып, видеоэлемтә ярдәмендә әңгәмә уздыру.

3.5.8. Башка җирлектә эшкә урнашу өчен, күчкәндә, эшсез гражданинга юллама бирү.

Эшсез гражданин кандидатурасын эш бирүче белән килештергәндә, халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга 26.02.2015, № 125н боерыкка 8 нче кушымта нигезендәге форма буенча эшкә юллама рәсмиләштерә һәм кулына бирә, нәтиҗәне Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 1 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшкә юллама рәсмиләштерү һәм эшсез гражданин кулына бирү.

3.5.9. Эшсез гражданин белән икенче урынга күчү турында килешү төзү.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече эшсез гражданинга, халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирә һәм эшсез гражданин белән эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчүдә булышу турында килешү (алга таба – күчү турында килешү) төзи, килешү халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 15 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: күчү турында килешү төзү.

3.5.10. Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына, күченгәндә, финанс ярдәме бирү турында яки эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итү.

Эшсез гражданин белән икенче урынга күчү турында килешү төзелгән очракта, халык мәшгульлеге үзәгенең эшсез гражданинга эшкә урнашу өчен юллама биргән белгече, эшсез гражданиннан яки эшсез гражданинның яңа яшәү урынындагы халык мәшгульлеге үзәгеннән бу Административ регламентның 2.5 пункты 1.5 пунктчасы белән күздә тотылган гариза кергәч, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына, халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә, финанс ярдәме бирү турында карар кабул итә. Финанс ярдәме бирелү турындагы карарны халык мәшгульлеге үзәге белгече бу Административ регламентка 7 нче кушымта нигезендәге форма буенча рәсмиләштерә һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән таныштырып, кул куйдыра. Күчү турында килешү булмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында бу Административ регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча карар рәсмиләштерә, баш тартуның сәбәпләрен, нигезләрен, финанс ярдәме бирелү тәртибен аңлата һәм эшсез гражданинны әлеге карар белән таныштырып, кул куйдыра.

Эшсез гражданин финанс ярдәме бирү турындагы яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турындагы карар белән кул куйдырып таныштырылмаган очракта, халык мәшгульлеге үзәгенең эшсез гражданинга эшкә урнашу өчен юллама биргән белгече финанс ярдәме бирү турында (бирүдән баш тарту турында) аның адресына язмача хәбәрнамә җибәрә.

Үтәлү срогы: процедура эшсез гражданиннан яки эшсез гражданинның яңа яшәү урынындагы халык мәшгульлеге үзәгеннән бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5 пунктчасы белән күздә тотылган гариза кергән моменттан башлап 3 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинга финанс ярдәме бирү турындагы яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турындагы карарны рәсмиләштерү, эшсез гражданинны карар белән таныштырып, кул куйдыру яисә финанс ярдәме бирү турында (бирүдән баш тарту турында) эшсез гражданинга язмача хәбәрнамә җибәрү.

3.5.11. Күчкәндә, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәмен билгеләү.

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәме гариза һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.2.1 – 1.5.2.6 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшыргач билгеләнә.

Эшсез гражданин яңа яшәү урынындагы халык мәшгульлеге үзәгенә № 515 Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча язылган гариза һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.2.1 – 1.5.2.6

пунктчаларында күрсәтелгән документлар белән мөрәҗәгать иткәч, һәм эшсез гражданин күчү турындагы килешүне күрсәткәч (эшсез гражданин һәм аның гаилә әгъзалары халык мәшгульлеге үзәге белгече халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, Татарстан Республикасы эчендәге башка җирлеккә күченгәндә), халык мәшгульлеге үзәге белгече бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.2.1 – 1.5.2.6 пунктчалары белән күздә тотылган документларның булуын һәм бу Административ регламентның 2.9 пунктына туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен һәм бу Административ регламентның 2.9 пункты белән күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, гариза һәм документлар кергәч (шул исәптән почта элемтәсе ярдәмендә яки электрон документлар рәвешендә), эшсез гражданинның яңа яшәү урынындагы халык мәшгульлеге үзәге белгече, документларны, гариза һәм документлар халык мәшгульлеге үзәгенә кергән көнне яисә (гариза һәм документлар халык мәшгульлеге үзәгенең эш вакыты беткәндә кергән очракта), башка җирлеккә күченгәндә эшкә урнашуга юллама биргән халык мәшгульлеге үзәгенә җибәрә. Гариза һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.2.1 – 1.5.2.6 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, электрон документлар рәвешендә, ял көннәрендә яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә кергән очракта – халык мәшгульлеге үзәгенең ял көненнән яки эшләми торган бәйрәм көннән соң килүче беренче эш көнендә.

Халык мәшгульлеге үзәгенә электрон документлар рәвешендә җибәрелгән документлар һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ һәм № 210-ФЗ Федераль законнар таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган (расланган) булырга тиеш.

Гаризаны, бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5.2.1 – 1.5.2.6 пунктчалары белән күздә тотылган документларны кушып, тапшыру турындагы хәбәрнамә белән заказлы хат итеп җибәргән очракта, финанс ярдәмен билгеләү турындагы гаризага эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документның нотариуста расланган күчермәсе өстәлә.

Халык мәшгульлеге үзәгенә гаризаны һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5, 1.5.2.1 – 1.5.2.6 пунктчалары белән күздә тотылган документларны тапшырганда, эшсез гражданинның вәкиле эшсез гражданинның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ, эшсез гражданин исеменнән эш йөртергә хокук бирүче ышанычнамә тапшыра.

№ 515 Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча язылган кергән гариза һәм бу Административ регламентның 2.5 пунктындагы 1.5.2.1 – 1.5.2.6 пунктчаларында күрсәтелгән документлар нигезендә, башка җирлеккә күченгәндә эшкә урнашуга юллама биргән халык мәшгульлеге үзәге белгече Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына эшсез гражданин турындагы мәгълүматларны эзләү параметрларын кертә һәм эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме бирү яки финанс ярдәме бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган

очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме билгеләү һәм аның күләме турында бу Административ регламентның 11 нче кушымтасына туры китереп, боерык проектын әзерли, аны халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесенә имзалауга тапшыра, шулай ук әлеге боерык белән эшсез гражданинны кул куйдырып таныштыра.

Эшкә урнашу өчен, башка җирлеккә күчкәндә эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, халык мәшгульлеге үзәге белгече башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәмен түләүдән баш тарту турында бу Административ регламентның 12 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча, боерык проектын әзерли, аны халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесенә имзалауга тапшыра, шулай ук әлеге боерык белән эшсез гражданинны кул куйдырып таныштыра.

Эшсез гражданин башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәмен билгеләү, аның сроклары һәм күләме турындагы яки финанс ярдәмен түләүдән баш тарту турындагы боерык белән кул куйдырып таныштырылмаган очракта, финанс ярдәмен түләү билгеләү (түләүдән баш тарту) хакында аның адресына язмача хәбәрнамә җибәрелә.

Үтәлү срогы: процедура гариза һәм документлар халык мәшгульлеге үзәгенә кергән моменттан башлап 5 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме билгеләү турындагы боерык яки эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәмен билгеләүдән баш тарту турындагы боерык, эшсез гражданинны финанс ярдәме билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) боерык белән таныштырып, кул куйдыру яисә финанс ярдәме билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) эшсез гражданинга язмача хәбәрнамә җибәрү.

3.5.12. Күченгәндә, эшсез гражданинга финанс ярдәмен күчерү.

Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме билгеләү турындагы боерык нигезендә, халык мәшгульлеге үзәге белгече, эш көннәрендә исәпләнүче 10 көнлек срок эчендә, халык мәшгульлеге үзәге счетына акча килгәннән соң, килгән акчаны эшсез гражданинның № 515 Тәртипкә 4 нче кушымталар нигезендәге форма буенча тутырылган гаризасында күрсәтелгән лицевой (банк) счетына күчерә.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече түләү документларында булган мәгълүматларны Дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертә.

Үтәлү срогы: процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап 5 минут эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: акча күчерү.

3.5.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

эшсез гражданинга башка җирлектә эшкә урнашу өчен 26.02.2015, № 125н боерыкка 8 нче кушымта нигезендәге форма буенча эшкә юллама бирү;

халык мәшгульлеге үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күчкәндә финанс ярдәме күрсәтү яисә аны күрсәтүдән дәлилле баш тарту.

3.6. Эшсез гражданинга дәүләт хезмәтен электрон рәвештә, КФҮ, ерактагы эш урыны аша күрсәтү.

3.6.1. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми.

3.6.2. Эшсез гражданин КФҮгә, ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны халык мәшгульлеге үзәгенә тапшыру гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, халык мәшгульлеге үзәге һәм КФҮ хезмәттәшлегенең тәртибе халык мәшгульлеге үзәге һәм КФҮ арасында төзелүче хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына.

3.7. Техник хаталарны төзәтү

Эшкә урнашуга юлламаны, яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдимен, яисә күчү турындагы килешүне, күчеп урнашу турындагы килешүне үзгәртеп рәсмиләштерү, элегрәк бирелгән эшкә урнашуга юлламада, яисә эш вариантлары исемлегендә, яисә халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдимендә, яисә күчү турындагы килешүдә, күчеп урнашу турындагы килешүдә җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язуларны, басмадагы ялгышлыкларны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Эшкә урнашуга юлламаны, яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдимен, яисә күчү турындагы килешүне, күчеп урнашу турындагы килешүне үзгәртеп рәсмиләштерү бу Административ регламентның 13 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча язылган теркәлгән гариза (эшсез гражданинга бирелгән техник хаталы документны өстәп) нигезендә башкарыла.

Халык мәшгульлеге үзәге белгече:

- техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (бу Административ регламентка 14 нче кушымта) терки;

- эшкә урнашуга юлламаны, яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдимен үзгәртеп рәсмиләштерә яисә күчү турындагы килешүгә, күчеп урнашу турындагы килешүгә өстәмә килешү рәсмиләштерә;

- гаризада күрсәтелгән ысул белән, эшкә урнашуга юлламаның, яисә эш вариантлары исемлегенең, яисә халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдименең үзгәртеп рәсмиләштерелүе, яисә күчү турындагы килешүгә, күчеп урнашу турындагы килешүгә өстәмә килешү рәсмиләштерелү турында эшсез гражданинга хәбәр итә.

Үтәлү срогы: процедура гариза теркәлгән моменттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән эшкә урнашуга юллама, яисә эш вариантлары исемлеге, яисә халык мәшгульлеге үзәге белгече тәкъдиме, яисә күчү турындагы килешүгә, күчеп урнашу турындагы килешүгә өстәмә килешү, әлеге документларның үзгәртеп рәсмиләштерелүе турында эшсез гражданинга хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлек халык мәшгульлеге үзәге директоры яки ул вәкаләт биргән хезмәткәр тарафыннан башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлек бу Административ регламентның, Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрларын алып баруның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 8 ноябрь, 2010 ел, № 972н боерыгы белән расланган тәртибенең (аларга мәгълүматлар бирү тәртибен, срокларын һәм формасын кертеп), дәүләт хезмәте алучыларның исәп документлары бланкларын тутыруга, алып бару һәм саклауга таләпләрнең һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшчәнлекне җайга салучы башка документларның үтәлүен һәм саклануын тикшерүләр уздыру юлы белән башкарыла.

Агымдагы контрольлекне башкаруның ешлыгы Халык мәшгульлеге үзәге директоры тарафыннан билгеләнә.

4.3. Халык мәшгульлегенә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә контрольлекне, эшсез гражданнарга социаль ярдәм өлешендәге дәүләт гарантияләреннән гайре, Министрлык халык мәшгульлегенә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә күзәтчелек һәм контрольлек буенча вәкаләтләр үтәү кысасында башкара.

Халык мәшгульлегенә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә контрольлек Министрлыкның планлы (планнан тыш) күчмә (документлар) тикшерүләр уздыруы юлы белән башкарыла.

4.4. Халык мәшгульлеге үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителүче (башкарылучы) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплы белгечләре закон белән билгеләнгән тәртиптә җавап тоталар.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Халык мәшгульлеге үзәге эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар халык мәшгульлеге үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр тәртиптә халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесенә шикаять белдерүгә хокуклы.

Халык мәшгульлеге үзәге җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Министрлыкка шуның белән шөгыльләнүче министр урынбасары яки министр исеменә бирелә.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең аларга туры китереп кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

халык мәшгульлеге үзәге, халык мәшгульлеге үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүче белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып КФҮ аша, Министрлыкның рәсми сайты (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru), халык мәшгульлеге үзәгенең рәсми сайтлары аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

